# ЮГАРЫ ЧУРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2024 елнын 21 ноябре №38

Физик затларның мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Югары Чура авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Советы территориясендә түләүгә мәҗбүри булган физик затларның салым милеген билгелргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

гаражлар һәм машина-урыннар;

һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелмәләр;

мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар. Ставка салым түләүче сайлаган бер гаражга яки машина-урынга карата билгеләнә;

2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата 0,2 процент

3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- составына ким дигәндә бер торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

- төзелеп бетмәгән объектлар, әгәр мондый объектларның проектлана торган максаты торак йорт булса;

4) 2025 елда – 1,2 процент; 2026 елда – 1,2 процент; 2027 елда – 1,2 процент гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-

эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган Исемлеккә кертелгән урыннарга карата.

5) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата 2,5 процент;

6) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

3. Ике фатирдан торган күп фатирлы бер катлы торак йортта фатирга милек хокукы булган физик затларга ташламаны бу фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнгән суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәрберсе өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир гомуми уртак милектә булса, ташлама суммасы уртак милектә катнашучыларның һәрберсе өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы аның исәбеннән башка исәпләнгән салым суммасыннан артмаска тиеш.

Югарыда күрсәтелгән ташламаны раслый торган документлар буларак, йортка кадастр паспорты яки җирле үзидарә органы тарафыннан расланган күп фатирлы бер катлы торак йортлар исемлеге тора.

4. Түбәндәге физик затларны милеккә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын;

3) күрсәтелгән гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) ата-аналары;

4) күрсәтелгән хәрби хезмәткәрләрнең махсус хәрби операциядә катнашу чорында махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары.

Әлеге карар максатлары өчен махсус хәрби операциядә катнашу чоры итеп затның салым чоры дәвамында мондый катнашу срогына карамастан махсус хәрби операциядә катнашуга җәлеп ителгән салым чоры танылa.

5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына, әлеге карар белән аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш.

6. Әлеге карар законлы көченә кергән көннән башлап, Югары Чура авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 20 ноябрьдэге 26 номерлы,«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 20 ноябрьдэге 26 номерлы 26 номерлы Югары Чура авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 сентябрьдэге 36 номерлы Югары Чура карарлары үз көчен югалта.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы: Р.Т.Мифтахов